**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **29 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче Әсәй авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Әсәй авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Әсәй авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Әсәй авылы Үзәк, Тау асты, Елга арты, Ясле, Мәктәп һәм Наратлы урамнары буенча вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Әсәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Әсәй авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Әсәй авылында (зиарат, мәчет, мәдәният йорты, ФАП, балалар бакчасы территорияләрендә) коры агач, куаклар кисү, чабу;
- Әсәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әсәй авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү;
- Әсәй авылында янгын сүндерү депосын тоту (электр энергиясе һәм җылылык өчен түләү).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы Идрисов З.Ә.